ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 1 августындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш); 2014, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Әлеге Законны куллану өлкәсе**

Әлеге Законның гамәлдә булуы физик затларга һәм юридик затларга – иҗтимагый берләшмәләргә алар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә янгыннарны профилактикалауга һәм (яисә) сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкаруга бәйле янгыннан ирекле саклау эшчәнлегендә катнашу хокукын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә кагыла.»;

2) 4 статьяда:
а) исемдә «иҗтимагый берләшмәләр» сүзләрен «янгыннан ирекле саклау иҗтимагый берләшмәләре» сүзләренә алмаштырырга;
б) «янгыннан ирекле саклау буенча иҗтимагый берләшмәләрнең» сүзләрен «янгыннан ирекле саклау иҗтимагый берләшмәләренең (алга таба – янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләре)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5 статья. **Янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләре мөлкәте**

Янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләре мөлкәте Россия Федерациясе законнары нигезендә башлангыч кертемнәр һәм әгъза буларак түләнә торган кертемнәр, әгәр аларны түләү тиешле янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәсе уставында каралган булса, аны гамәлгә куючыларның кертемнәре, ихтыярый кертемнәр һәм иганәләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләренә күрсәтелә торган ярдәм чаралары исәбеннән әлеге уставка таянып үткәрелә торган чаралардан кертемнәр һәм Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка кертемнәр (шул исәптән, янгыннан мөлкәтне һәм (яисә) граждан җаваплылыгын иминләштерүне гамәлгә ашыручы иминият оешмалары акчалары) нигезендә туплана.»;

4) 7 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 8 статьяда «Янгыннан ирекле саклау командалары (дружиналары)» сүзләрен «Ирекле янгын сүндерү бүлекчәләре» сүзләренә алмаштырырга;

6) 9 статьяның 1 пунктында «янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр хезмәткәрләрен һәм анда катнашырга теләүчеләрне» сүзләрен «янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләренең ирекле янгын сүндерүчеләрен һәм янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләрен» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 16 ноябрь
№ 110-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ